**Карлы авыл җирлеге җир кишәрлекләрен Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе составына кертү юлы белән Буа шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларга бәяләмә**

**Уздыру датасы:** 03 август 2026 ел
**Уздыру урыны:** Буа шәһәре, Жорес урамы, 110 А й, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 2 кат (утырышлар залы)
**Уздыру вакыты:** 10:00 сәг.

Гавами тыңлаулар предметы: Карлы авыл җирлеге җир кишәрлекләрен Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе составына кертү юлы белән Буа шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү.

Гавами тыңлаулар үткәрү өчен нигез: Буа муниципаль районының Буа шәһәре башлыгының «Буа шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында» 2026 елның 17 июлендәге 7 номерлы карары.

Гавами тыңлаулар уздыру турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Буа шәһәре муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында бастырылган, шулай ук Буа муниципаль районының РТ рәсми сайтында урнаштырылган, ягъни гавами тыңлаулар уздыру турындагы мәгълүмат халыкка җиткерелгән.

Гавами тыңлауларга әзерлек чорында Карлы авыл җирлеген җир кишәрлекләрен муниципаль берәмлек территориясе составына кертү юлы белән Буа шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелмәде. 2026 елның 3 августында гавами тыңлаулар вакытында гавами тыңлауларда катнашучылардан искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кермәде, гражданнарның хокукларын бозу һәм аларның мәнфәгатьләрен кысу ачыкланмады.

Буа шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен Карлы авыл җирлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Буа шәһәре муниципаль берәмлегенә кертү юлы белән үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем, бирелгән материалларны, гавами тыңлаулар беркетмәсен карап, гавами тыңлаулар үткәрү процедурасы үтәлгән дип саный.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр:

1. Гавами тыңлауларны узган дип танырга.

2. Карлы авыл җирлеге җир кишәрлекләрен Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе составына кертү юлы белән Буа шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү инициативасын хупларга.

3. Гавами тыңлауларның бәяләмәсен һәм материалларын халыкка җиткерергә.

Кушымта:
2026 елның 03 августындагы гавами тыңлаулар беркетмәсе
Эш төркеме әгъзаларының имзалары:

_______________ А.М.Сафин
_______________ С.А. Зайцева
_______________ Р.М. Гыйлфанов
_______________ Р.Р. Хәмидуллин
_______________ Р.З. Сабитова
_______________ А.А. Таканаева